| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 29.12.2022 | г.Зеленодольск | № 236 |

Зеленодольск муниципаль районы Советының « Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары, «Зеленодольск муниципаль районы контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе рәисе, аудиторлары, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары өчен түләү күләмнәрен билгеләү турында» 2020 елның 7 сентябрендәге 516 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 23 октябрендәге 13 номерлы, 2021 елның 17 декабрендәге 118 номерлы, 2022 елның 16 сентябрендәге 198 номерлы карарларындагы үзгәрешләр белән)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының « Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары, «Зеленодольск муниципаль районы контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе рәисе, аудиторлары, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль

хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары өчен түләү күләмнәрен билгеләү турында» 2020 елның 7 сентябрендәге 516 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 23 октябрендәге 13 номерлы, 2021 елның 17 декабрендәге 118 номерлы, 2022 елның 16 сентябрендәге 198 номерлы карарларындагы үзгәрешләр белән) (алга таба- Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта:

1.1) беренче абзацта «2022 елның 1 октябреннән» сүзләрен «2023 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1.2) икенче абзацта «36 366 (утыз алты мең өч йөз алтмыш алты) сум күләмендә һәм айлык акчалата бүләкләү 87 294 (сиксән җиде мең ике йөз туксан дүрт) сум күләмендә» сүзләрен «38 585 (утыз сигез мең биш йөз сиксән биш) сум күләмендә һәм айлык акчалата бүләкләү 92 620 (туксан ике мең алты йөз егерме) сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга һәм «акчалата гомуми хезмәт хакы» сүзләрен «айлык акчалата түләүне һәм айлык акчалата бүләкләүне үз эченә алган гомуми акчалата түләүләр күләме» сүзләренә алмаштырырга;

1.3) өченче абзацта «32 728 (утыз ике мең җиде йөз егерме сигез) сум күләмендә һәм айлык акчалата бүләкләү 35 285 (утыз биш мең ике йөз сиксән биш) сум күләмендә» сүзләрен «34 725 (утыз дүрт мең җиде йөз егерме биш) сум күләмендә һәм айлык акчалата бүләкләү 37 438 (утыз җиде мең дүрт йөз утыз сигез) сум күләмендә» сүзләренә алыштырырга;

1.4) дүртенче абзацта «32 728 (утыз ике мең җиде йөз егерме сигез) сум күләмендә һәм айлык акчалата бүләкләү 35 285 (утыз биш мең ике йөз сиксән биш) сум күләмендә» сүзләрен, «34 725 (утыз дүрт мең җиде йөз егерме биш) сум күләмендә һәм айлык акчалата бүләкләү 37 438 (утыз җиде мең дүрт йөз утыз сигез) сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.5) бишенче абзацта «24 634 (егерме дүрт мең алты йөз утыз дүрт) сум күләмендә һәм айлык акчалата бүләкләү 16 174 (уналты мең йөз җитмеш дүрт) сум күләмендә» сүзләрен «26 137 (егерме алты мең йөз утыз җиде) сум күләмендә һәм айлык акчалата бүләкләү 17 161 (унҗиде мең йөз алтмыш бер) сум күләмендә» сүзләренә алыштырырга;

2) 2 пунктта:

2.1) беренче абзацта «2022 елның 1 октябреннән» сүзләрен «2023 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2.2) икенче абзацта «36 366 (утыз алты мең өч йөз алтмыш алты) сум күләмендә » сүзләрен «38 585 (утыз сигез мең биш йөз сиксән биш) сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

2.3) өченче абзацта «32 728 (утыз ике мең җиде йөз егерме сигез) сум күләмендә» сүзләрен «34 725 (утыз дүрт мең җиде йөз егерме биш) сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

2.4) дүртенче абзацта «32 728 (утыз ике мең җиде йөз егерме сигез) сум күләмендә» сүзләрен «34 725 (утыз дүрт мең җиде йөз егерме биш) сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

2.5) бишенче абзацта «24 634 (егерме дүрт мең алты йөз утыз дүрт) сум күләмендә» сүзләрен «26 137 (егерме алты мең йөз утыз җиде) сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «2022 елның 1 октябреннән» сүзләрен «2023 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4). «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре» кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Зеленодольск муниципаль
районы Советының 2022 елның
16 сентябрендәге 198 номерлы
карарына
кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ ВАЗЫЙФА ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМЕ

| **Муниципаль хезмәт вазыйфалары төркемнәренең атамасы** | **Айлык вазыйфаи оклад күләме, сум** |
|---|---|
| Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе | 38 064 |
| Зеленодольск муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары | 35 146 |
| Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | 34 512 |
| «Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» МУ, «Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы » МУ җитәкчеләре | 34 385 |
| «Зеленодольск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МУ, «Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы »МУ җитәкчеләре урынбасарлары | 31 213 |
| Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүче | 31 974 |
| Мөстәкыйль бүлек (идарә) начальнигы, Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының, Зеленодольск муниципаль районының башка җирле үзидарә органының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе | 26 138 |
| Мөстәкыйль бүлек (идарә) начальнигы урынбасары, Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының, Зеленодольск муниципаль районының башка җирле үзидарә органының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы киңәшчесе, | 21 570 |

| | |
|---|---|
| Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы ярдәмчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе киңәшчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты идарә составындагы бүлек начальнигы | |
| Сектор мөдире | 20 048 |
| Баш белгеч | 19 286 |
| Әйдәп баручы белгеч | 18 144 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 16 241 |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**